КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2019 ел, 20 декабрь г.Казань № 118

Татарстан Республикасы территориясендә инвестиция проектларын тормышка ашыруда «бер тәрәзә» принцибы буенча ярдәм итү буенча инвестиция эшчәнлеге субъектларының үзара хезмәттәшлеге регламентын раслау турында

«Татарстан Республикасында дәүләти-хосусый партнерлык турында» 2011 елның 1 августындагы 50-ТРЗ номерлы, «Татарстан Республикасында инвестиция эшчәнлеге турында» 1998 елның 25 ноябрендәге 1872 номерлы, «Татарстан Республикасында чит ил инвестицияләре турында» 1994 елның 19 июлендәге 2180-XII номерлы Татарстан Республикасы законнарын гамәлгә ашыру һәм Татарстан Республикасында уңайлы инвестиция климатын тәэмин итү буенча Россия Федерациясе субъекты башкарма хакимияте органнары эшчәнлеге стандартын кертү өчен шартлар тудыру максатларында Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Каррарга теркәлгән Татарстан Республикасы территориясендә инвестиция проектларын тормышка ашыруда «бер тәрәзә» принцибы буенча ярдәм итү буенча инвестиция эшчәнлеге субъектларының үзара хезмәттәшлеге регламентын (алга таба – Регламент) расларга.

2. Татарстан Республикасының Инвестицион үсеш агентлыгын «бер тәрәзә» принцибы буенча инвестиция проектларын алып бару системасының эшләвен тәэмин итә торган Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең вәкаләтле башкарма органы итеп билгеләргә, шул исәптән Татарстан Республикасының Инвестицион советы проектларын карап тикшерүне да кертеп (алга таба – вәкаләтле орган).

3. Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләренең җирле үзидарә органнарына Регламент нигезендә инвестиция проектларын гамәлгә ашыруда инвестицион эшчәнлек субъектларына ярдәм күрсәтергә тәкъдим итәргә.

4. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының түбәндәге карарлары үз көчен югалткан дип танырга:

«Татарстан Республикасы территориясендә инвестиция проектларын тормышка ашыруда «бер тәрәзә» принцибы буенча булышлык күрсәтү буенча инвестиция эшчәнлеге субъектлары арасында үзара хезмәттәшлек итүнең вакытлыча регламентын раслау турында» 2013 ел, 20 февраль, 115 нче;

«Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы территориясендә инвестиция проектларын тормышка ашыруда «бер тәрәзә» принцибы буенча булышлык күрсәтү буенча инвестиция эшчәнлеге субъектлары арасында үзара хезмәттәшлек итүнең вакытлыча регламентын раслау турында» 2013 ел, 20 февраль, 115 нче карарына үзгәреш кертү хакында» 2013 ел, 11 май, 315 нче карары.

5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Татарстан Республикасының Инвестицион үсеш агентлыгына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры
вазыйфаларын башкаручы Р.К.Нигъмәтуллин

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2019 ел, 20 февраль, 118 нче
карары белән расланды

**Татарстан Республикасы территориясендә инвестиция проектларын тормышка ашыруда «бер тәрәзә» принцибы буенча ярдәм итү буенча инвестиция эшчәнлеге субъектларының үзара хезмәттәшлеге регламенты**

1. Гомуми нигезләмәләр

1.1. Татарстан Республикасы территориясендә инвестиция проектларын тормышка ашыруда «бер тәрәзә» принцибы буенча ярдәм итү буенча инвестиция эшчәнлеге субъектларының үзара хезмәттәшлегенең әлеге регламенты (алга таба – Регламент) инвестиция проектларын гамәлгә ашырганда һәм дәүләт ярдәме күрсәткәндә инвестиция эшчәнлеге субъектларының үзара хезмәттәшлеге тәртибен билгели.

1.2. Әлеге Регламент максатлары өчен түбәндәге терминнар кулланыла:

капиталь төзелеш объекты – инвестиция проектын гамәлгә ашыру максатларында инвестор тарафыннан сатып алынган яки арендага алынган җитештерү, склад һәм административ биналар, төзелмәләр һәм корылмалар яисә күрсәтелгән объектлар булган җир кишәрлеге;

буш җир кишәрлекләре – инвестиция проектын тормышка ашыру максатларында инвестор тарафыннан сатып алынган яки арендага алынган муниципаль берәмлекләрдә төзелеш булмаган җир кишәрлекләре;

инвестиция эшчәнлеге субъектлары – инвесторлар, заказчылар, подрядчылар, инвестиция эшчәнлеге объектларыннан файдаланучылар һәм инвестиция эшчәнлегендә башка катнашучылар сыйфатында булган, шул исәптән махсус икътисадый зона территориясендә, алга киткән социаль-икътисадый үсеш, сәнәгать мәйданчыклары, технопарклар, бизнес-инкубаторлар, сәнәгать парклары, технополислар территорияләрендә инвестиция эшчәнлеге алып баручы физик һәм юридик затлар, шул исәптән чит илнеке, шулай ук дәүләтләр һәм халыкара оешмалар

инвестиция мәйданчыгы – максатчан үзләштерү һәм перспектив үсеш өчен билгеләнгән, өченче затлар хокукларыннан ирекле локальләштерелгән территорияләр;

инвестиция проекты – инвестицияләрне гамәлгә ашыруның икътисадый максатчанлыгын, күләмен һәм срокларын нигезләү, шул исәптән закон нигезендә эшләнгән проект-смета документациясе, шулай ук инвестицияләрне, шул исәптән экспортлауга һәм җитештерелә торган продукциянең, товарларның, хезмәт күрсәтүләренең конкурентлылык сәләтен үстерүгә юнәлдерелгән инвестицияләрне гамәлгә ашыру буенча практик гамәлләрне тасвирлауны (бизнес-планны да кертеп);

Татарстан Республикасы Инвестиция советы (алга таба – Инвестиция советы) – Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасының Инвестиция советын төзү турында» 2012 елның 5 июлендәге ПУ-538 номерлы

Указы нигезендә төзелгән Татарстан Республикасы икътисадына инвестицияләр җәлеп итү мәсьәләләре буенча коллегиаль киңәшмә органы»;

инвестицияләр – акча, кыйммәтле кәгазьләр, башка мөлкәт, шул исәптән мөлкәт хокуклары, табыш алу һәм (яки) башка уңай нәтиҗәгә ирешү максатларында эшмәкәрлек һәм (яки) башка эшчәнлек объектларына кертелә торган акчалата бәяле башка хокуклар;

инвестор – Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасы законнары нигезендә инвестицияләр рәвешендә үз, заем яки җәлеп ителгән акчаны кертүне гамәлгә ашыручы һәм аларны максатчан куллануны тәэмин итүче инвестиция эшчәнлеге субъекты;

инвестиция проектының инициаторы (алга таба – инициатор) – Татарстан Республикасы территориясендә инвестиция проектын гамәлгә ашыруга тәкъдим итүче физик яки юридик зат;

Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең башкарма органы – Татарстан Республикасы карамагындагы мәсьәләләр һәм Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасы уртак карамагындагы мәсьәләләр буенча Татарстан Республикасы вәкаләтләренә кертелгән һәм Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең башкарма органнары структурасына кертелгән мәсьәләләр буенча дәүләт идарәсен үз компетенциясе чикләрендә гамәлгә ашыручы Татарстан Республикасы дәүләт органы;

«бер тәрәзә» принцибы – вәкаләтле орган тарафыннан инвестиция проектын алып бару һәм аны гамәлгә ашыруның барлык этапларында ведомствоара үзара нәтиҗәле эш итүне оештыру;

инвестиция проекты резюмесы – әлеге Регламентка 1 нче кушымта нигезендә рус һәм/яки инглиз телләрендәге форма буенча, Татарстан Республикасы территориясендә аны гамәлгә ашыруның төп шартларын бәян итеп инициатор тәкъдим итә торган инвестиция проекты турында кыскача мәгълүмат;

инвестицион проектны гамәлгә ашыру инициаторы-вәкаләтле орган эшчәнлеге

инвестиция проектын алып бару – вәкаләтле органның инициатор тарафыннан инвестиция проектын уңышлы гамәлгә ашыруны оештыруга юнәлдерелгән эшчәнлеге.

1.3. Татарстан Республикасы территориясендә инвестиция проектларын гамәлгә ашыру максатларында вәкаләтле орган:

Инвестиция проектларын алып бару системасының эшләвен тәэмин итә, шул исәптән проектларны Инвестиция советы карап тикшерүне дә кертеп;

Татарстан Республикасы территориясендә инвестиция проектларын тормышка ашыру өчен документлар әзерләгәндә инвесторларга консультация, мәгълүмати һәм хокукый ярдәм күрсәтә;

инвестиция проектларын тормышка ашырганда финанс-кредит оешмалары белән хезмәттәшлек итә;

инвесторлар тарафыннан тәкъдим ителгән инвестиция проектларына экспертиза үткәрә һәм инвесторга инвестиция проектын гамәлгә ашыруның мөмкин механизмнары турында тәкъдимнәр кертә (аны гамәлгә ашыру максатчан булган очракта);

социаль-мәдәни һәм коммуналь-көнкүреш билгеләнешендәге объектның, масштаблы инвестиция проектының Татарстан Республикасы Президенты боерыклары нигезендә сәүдә үткәрмичә җир кишәрлеген арендага бирү өчен Татарстан Республикасы Җир кодексы белән билгеләнгән критерийләргә туры килүен нигезли торган документларны кабул итүне һәм карап тикшерүне гамәлгә ашыра;

социаль-мәдәни һәм коммуналь-көнкүреш билгеләнешендәге объектларны урнаштыру, масштаблы инвестицион проектларны гамәлгә ашыру өчен Татарстан Республикасы Президенты күрсәтмәләре нигезендә сәүдә үткәрмичә җир кишәрлеген арендага бирү турындагы үтенечнамәләрне кабул итүне гамәлгә ашыра;

әлеге тәкъдимнәрне эшләү инициаторы булып Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең башкарма органы торса, инвестиция проектларын, шул исәптән дәүләт-хосусый партнерлык рәвешендә гамәлгә ашыру турындагы тәкъдимнәрне гавами партнет белән бергә алдан карап тикшерүне гамәлгә ашыра;

инвестиция проектларының нәтиҗәлелеген, шул исәптән дәүләт-хосусый партнерлык рәвешендә дә, гавами партнер буларак та бәяли, һәм бу проектның федераль закон нигезләмәләре нигезендә чагыштырма өстенлекләрен билгели;

Татарстан Республикасы дәүләт-хосусый партнерлык турында килешү төзү хокукына конкурслар үткәрү өчен конкурс документларының гавами партнерына килештерүне гамәлгә ашыра;

федераль законнарга һәм Татарстан Республикасы законнарына каршы килми торган инвестицион проектларны гамәлгә ашыруга ярдәм итүче башка рәвешләрне гамәлгә ашыра.

1.4. Инвестиция советын үткәргәнче, инициатор белән килештереп, вәкаләтле орган потенциаль инвесторларга инвестиция проектлары презентациясен гамәлгә ашыра. Инвесторның инвестиция проектында катнашу белән кызыксынуы булганда, вәкаләтле орган инициатор белән килештереп, инвесторга инвестиция проекты турында кирәкле мәгълүмат бирергә хокуклы.

1.5. Вәкаләтле орган, инициатор белән килешеп, Татарстан Республикасы катнашында «бер тәрәзә» принцибы нигезендә, аларны әзерләү һәм гамәлгә ашыруның барлык стадияләрендә инвестиция проектларын алып баруны гамәлгә ашыра.

## 2. Инвестиция проектын алып бару

2.1. Инвестиция проектын «бер тәрәзә» принцибы буенча алып бару өчен инициатор вәкаләтле органга әлеге Регламентка 2 нче кушымта нигезендә инвестиция проектын алып бару буенча ярдәм күрсәтү турында гариза (алга таба – гариза), шулай ук әлеге Регламентка 1 нче кушымта нигезендә инвестиция проекты резюмесын җибәрә. Документларны тапшыру шул исәптән «Интернет» мәгълүмати-телекоммуникация челтәре аша да гамәлгә ашырыла ала.

Әлеге Регламентның 1.5 пунктында каралган инвестиция проектларын гамәлгә ашыруда мәгълүмати, консультация, хокукый ярдәм һәм башка ярдәм чаралары вәкаләтле орган тарафыннан инвестиция проекты резюмесында күрсәтелгән мәгълүмат нигезендә гамәлгә ашырыла.

Вәкаләтле орган Инвестиция советын үткәргәнче инициаторга инвестиция проектын тормышка ашыру өчен мәйданчыклар һәм финанслау чыганаклары җыюда, бизнес-планны формалаштыру өчен кирәкле мәгълүматлар алуда, шулай ук җитештерүгә планлаштырылган продукцияне сатуның потенциаль базарлары турында мәгълүмат җыюда ярдәм күрсәтә.

2.2. Гариза һәм инвестиция проекты резюмесын алганнан соң вәкаләтле орган гариза һәм инвестиция проекты резюмесын алган көннән соң эш көннәрендә исәпләнгән ике көн эчендә аларны карап тикшерә һәм җаваплы башкаручыны билгели. Вәкаләтле органга тапшырыла торган мәгълүматларның дөреслеге өчен инициатор җавап бирә.

2.3. Вәкаләтле орган гариза һәм инвестиция проекты резюмесын алган көннән соң эш көннәрендә исәпләнгән ун көн эчендә алынган мәгълүматны анализлый һәм Татарстан Республикасы территориясендә инвестиция проектын гамәлгә ашыруның максатчанлыгы яисә файдасызлыгы турында башлангыч бәяләмә бирә.

2.4. Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең башкарма органы бәяләмәсен алу максатларында вәкаләтле орган, инвестицияле проект резюме алган көннән башлап эш көннәрендә исәпләнгән ике көн эчендә аны Татарстан Республикасы территориясендә инвестиция проектын гамәлгә ашыруның максатчанлыгы яисә файдасызлыгы турында алдан бәяләмә бирү өчен проектның тармак билгеләнеше нигезендә Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органына җибәрә.

2.5. Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең башкарма органы соратуны алган көннән соң эш көннәрендә исәпләнгән биш көн эчендә вәкаләтле орган адресына соратып алына торган мәгълүматны – инвестиция проектын тормышка ашыруның максатчанлыгы яисә файдасызлыгы турында бәяләмә җибәрә.

Бәяләмәләр, Татарстан Республикасы территориясендә инвестиция проектын гамәлгә ашыруның максатчанлыгы яисә файдасызлыгы сәбәпләрен күрсәтеп, дәлилләнгән булырга тиеш.

Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең башкарма органы тарафыннан вәкаләтле орган адресына инвестиция проекты буенча билгеләнгән вакытка бәяләмә бирелмәсә, Татарстан Республикасы территориясендә инвестиция проектын гамәлгә ашыру максатка ярашлы дип танылa.

2.6. Вәкаләтле орган инвестиция проекты буенча бәяләмә алган көннән соң эш көннәрендә исәпләнгән өч көн эчендә Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең башкарма органы тәкъдим иткән мәгълүматка анализ ясый һәм Татарстан Республикасы территориясендә инвестиция проектын гамәлгә ашыруның максатчанлыгы яисә файдасызлыгы турында инициаторга җавап җибәрә.

Барлык җаваплар дәлилләнгән булырга һәм инициатор дәгъва итә торган дәүләт ярдәме кораллары турында мәгълүматны үз эченә алырга тиеш.

Документлар Татарстан Республикасы территориясендә инвестиция проектын гамәлгә ашыруның файдасызлыгы турында җавап җибәргәннән соң 10 эш көне эчендә вәкаләтле орган тарафыннан инициаторга кире кайтарыла.

Әгәр Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең тармак башкарма органнарының фикере туры килмәсә, Татарстан Республикасы территориясендә

инвестицияпроектын гамәлгә ашыруның максатчанлыгы турындагы мәсьәләне карап тикшерү Инвестиция советы утырышына чыгарыла.

2.7. Вәкаләтле органнардан Татарстан Республикасы территориясендә инвестиция проектын гамәлгә ашыруның максатчанлыгы турында яисә әлеге мәсьәләне Инвестиция советы утырышында карап тикшерү турында җавап алган инициатор инвестиция проектын алга таба «бер тәрәзә» принцибы буенча вәкаләтле орган тарафыннан алып бару максатларында инвестиция проекты тәкъдир итүне тәкъдим итәргә хокуклы.

2.8. Әлеге Регламентның 2.7 пунктында каралган мәгълүмат инициатордан алынган көннән соң 30 көн эчендә вәкаләтле орган инвестиция проектын Инвестиция советы каравына чыгара.

2.9. Инвестиция советы беркетмәсен алган көннән алып ике көн эчендә вәкаләтле орган Инвестиция советы тарафыннан инвестиция проектын карап тикшерү йомгаклары буенча кабул ителгән карар турында инициатор адресына хәбәр җибәрә.

2.10. Инвестиция советы Татарстан Республикасы территориясендә инвестиция проектын гамәлгә ашыруның максатчанлыгы турында уңай карар кабул ителгән очракта, инициатор инвестиция проектын алга таба тормышка ашыруга һәм, әгәр теркәү тормышка ашырылмаган булса, юридик затны теркәүгә әзерлек турында карар кабул итәргә хокуклы.

2.11. Инвестиция проекты җитештерү һәм эш урыннары төзүдән, бизнес-план белән билгеләнгән максатларны үтәүдән соң тормышка ашырылган дип санала.

## 3. Инвесторга «бер тәрәзә» принцибы буенча инвестиция проектларын тормышка ашыруда ярдәм итүнең өстәмә процедураларын гамәлгә ашыру

3.1. Инвестор инициативасы буенча инвестиция проектын тормышка ашыру барышында вәкаләтле орган түбәндәге сораулар буенча консультация ярдәме күрсәтә:

инвестиция проектының капиталь төзелеш объектын яки буш җир кишәрлекләрен төзү/оештыру;

инвестиция проектының бизнес-планын һәм техник-икътисадый нигезләмәсен анализлау;

кадрлар белән тәэмин итү;

инвестиция проектын тормышка ашыру барышында барлыкка килә торган мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлдерелгән сөйләшүләр, очрашулар, киңәшмәләр, консультацияләрне оператив оештыру;

дәүләт хакимиятенең федераль һәм төбәк башкарма органнары, муниципаль берәмлекләрнең җирле үзидарә органнары һәм башка оешмалар белән үзара хезмәттәшлек;

мәгълүмати ярдәм һәм логистика күрсәтү;

инвестиция эшчәнлегенә караган бүтән мәсьәләләр буенча.

## 4. Инвесторны проектлап озата бару

4.1. Вәкаләтле орган инвесторга түбәндәге сораулар буенча консультация ярдәме үткәрә:

эшчәнлек юнәлешләрен киңәйтү;

яңа эшчәнлек юнәлешләре булдыру;

төбәк, федераль һәм халыкара масштабтагы эшлекле чараларда катнашу.

4.2. Инвестор җитештерүне алга таба үстерергә һәм киңәйтергә әзер булган очракта озата бару әлеге Регламентның 2 яки 3 бүлеге нигезендә гамәлгә ашырыла.

Татарстан Республикасы территориясендә инвестиция проектларын тормышка ашыруда «бер тәрәзә» принцибы буенча ярдәм итү буенча инвестиция эшчәнлеге субъектларының үзара хезмәттәшлеге регламентыны 1 нче кушымта

Форма

**Инвестиция проекты резюмесы**

| Т/с | Пункт исеме | Тутыру буенча аңлатмалар һәм киңәшләр |
|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 |
| 1. | Проектның исеме | Проектның уникаль исеме күрсәтелә |
| 2. | Мәгълүматны актуальләштерү датасы | Резюмеларда тәкъдим ителгән мәгълүмат актуаль булган дата күрсәтелә |
| 3. | Проектның тасвирламасы | Проектның кыскача тасвирламасы китерелә, аның максатлары, бурычлары, төзелә торган (төзекләндерелә торган) объектның максатчан билгеләнеше, планлаштырыла торган икътисадый һәм социаль эффекты күрсәтелгән |
| 4. | Проектның иҗтимагый инфраструктурасы төре | Проектның иҗтимагый инфраструктурасы төре күрсәтелә: транспорт, коммуналь хуҗалык, җитештерү инфраструктурасы, куркынычсызлык инфраструктурасы, социаль инфраструктура, туризм инфраструктурасы, мәгълүмати инфраструктура, башкалар (проект иҗтимагый инфраструктурага караган очракта) |
| 5. | Проектның инициаторы | Проектның инициаторы – федераль яки төбәк дәүләт хакимияте органы, муниципаль берәмлекнең җирле үзидарә органы һәм (яки) юридик зат, шул исәптән чит ил юридик зат күрсәтелә |
| 6. | Инвестицияләр объектлары | Инвестицияләү объекты күрсәтелә |
| 7. | Инвестицияләрнең гомуми күләме, млн сум | НДСны исәпкә алып, сумнарда капиталь кертемнәрнең гомуми күләме күрсәтелә |
| 8. | Федераль бюджет акчалары исәбеннән | Федераль бюджет акчалары исәбеннән финанслау күздә тотыла торган капиталь кертемнәр күләме |

| 1 | 2 | 3 |
|---|---|---|
| | финанслана торган (финанслауга планлаштырыла торган) инвестицияләр күләме, млн сум | күрсәтелә |
| 9. | Федераль бюджет акчалары исәбеннән финанслана торган инвестицияләр объектлары | Аларны финанслау федераль бюджет акчалары исәбеннән гамәлгә ашырылачак (гамәлгә ашырыла торган) инвестицияләр объектлары әлеге форманың 6 пункты нигезендә күрсәтелә |
| 10. | Татарстан Республикасы бюджеты акчалары исәбеннән финанслана торган (финанслауга планлаштырыла торган) инвестицияләр күләме, млн сум | Финанслау Татарстан Республикасы берләштерелгән бюджеты акчалары исәбеннән (төбәк һәм муниципаль бюджетларга бүлеп бирелгән) финанслана торган капиталь салулар күләме күрсәтелә |
| 11. | Татарстан Республикасы бюджеты акчалары исәбеннән финанслана торган инвестицияләр объектлары | Әлеге форманың 6 пункты нигезендә Татарстан Республикасы берләштерелгән бюджеты акчалары исәбеннән финанслауны гамәлгә ашыру планлаштырылган (гамәлгә ашырыла торган) инвестицияләр объектлары күрсәтелә |
| 12. | Бюджеттан тыш чыганаклар исәбеннән финанслана торган (финанслауга планлаштырыла торган) инвестицияләр күләме, млн сум | Бюджеттан тыш чыганаклар исәбеннән финанслау күздә тотылган капиталь кертемнәр күләме күрсәтелә (бюджеттан тыш чыганаклар җәлеп итеп проектны тормышка ашыру өчен кирәк булган акчалар күләме күрсәтелә) |
| 13. | Бюджеттан тыш чыганаклар исәбеннән финанслана торган инвестицияләр объектлары | Инвестицияләр объектлары әлеге форманың 6 пункты нигезендә күрсәтелә, аларны финанслау бюджеттан тыш чыганаклар исәбеннән күздә тотыла |
| 14. | Гамәлдәге инвестицияләр күләме, млн сум | Әлеге форманың 8, 10, 12 пунктлары нигезендә, чыганаклары буенча бүлеп, әлеге форманың 2 пунктында күрсәтелгән датага фактта гамәлгә ашырылган инвестицияләр күләме күрсәтелә |
| 15. | Проектны тормышка ашыруның хокукый формасы | Түбәндә китерелгән бер яки берничә вариант күрсәтелә:<br>проект финанслана, шул исәптән Россия Федерация- |

| 1 | 2 | 3 |
|---|---|---|
| | | се Инвестиция фонды акчалары исәбеннән;<br>проект белән Татарстан Республикасы Хөкүмәте гарантиясен бирү күздә тотыла;<br>проект дәүләт-хосусый партнерлык турында Россия Федерациясе субъекты законы кысаларында гамәлгә ашырыла;<br>проект нигезендә хосусый инвестордан төзелгән объектларга милек хокукын проект тәмамланганнан соң дәүләт яки муниципаль идарә органнарына күчүне күздә тота;<br>проект кысаларында төзелә торган объектлар салым преференцияләре предметы булып тора (булганда күрсәтергә);<br>объект федераль (төбәк) программаларга кертелгән (булганда күрсәтергә);<br>инвестор проектны гамәлгә ашыруның башка ысулын күрсәтә |
| 16. | Дәүләт-шәхси партнерлык формасы | Түбәндә китерелгән вариантларның берсе күрсәтелә:<br>түләүне кичектереп түләү шарты белән дәүләт контракты;<br>инвестиция йөкләмәләре белән аренда;<br>концессион килешү;<br>тормыш циклы контракты;<br>энергосервис контракты;<br>башка |
| 17. | Проектны тормышка ашыру стадиясе | Түбәндә китерелгән бер яки берничә вариант күрсәтелә:<br>проект концепциясе (идеяләре) булу;<br>хакимият органы проектны гамәлгә ашыру турында карар кабул итте (норматив хокукый актның датасын һәм номерын күрсәтергә);<br>хакимият органы тарафыннан проект концепциясе әзерләнде;<br>проектны оештыру буенча консультант (консультантлар) сайлап алуга конкурс (конкурслар) игълан ителде;<br>консультант тарафыннан конкурс документларын әзерләү буенча эшләр башкарылды;<br>инвестор сайлап алуга конкурс игълан ителде;<br>проект инвесторына конкурска йомгак ясалды, җиңүче сайланды;<br>конкурста җиңүче проект инициаторы – хакимият органы белән килешү төзеде; |

| 1 | 2 | 3 |
|---|---|---|
| | | финанс ябылу стадия;<br>инвестор проектны тормышка ашыруга кареште |
| 18. | Проект буенча документлар булу | Проект буенча булган документлар күрсәтелә: Татарстан Республикасы Хөкүмәте карарлары һәм/яки башкарма хакимиятнең федераль органнары карарлары, проект концепциясе, техник-икътисадый нигезләү, бизнес-план, проект-смета документлары, кирәкле килештерү һәм рөхсәтләр, конкурс документлары, дәүләт экспертизасы бәяләмәләре, файдалануга тапшыру актлары һәм б.ш. |
| 19. | Хезмәткәрләрнең исемлек буенча уртача саны | Төзелә торган эш урыннары саны күрсәтелә |
| 20. | Хезмәткәрләрнең уртача айлык хезмәт хакы | Хезмәткәрләрнең хезмәт хакы күләме күрсәтелә |
| 21. | Проектны гамәлгә ашыру вакыты | Проектның инвестиция фазасының планлаштырылган яки факттагы башлангыч датасы (объектны төзегәндә яки реконструкцияләгәндә) һәм объектны файдалануга тапшыруның планлаштырылган яки факттагы датасы күрсәтелә |
| 22. | Бюджет нәтиҗәлелеге күрсәткече | Федераль бюджетның һәм Татарстан Республикасы берләштерелгән бюджетының салым һәм салым булмаган керемнәренең, бюджеттан тыш фондларның керемнәре (чорны, шулай ук еллар буенча вакытлыча динамиканы күрсәтеп) исәп-хисап һәм фактта күләме, булдырылган (булдыруга планлаштырыла торган) эш урыннары саны, эш хакының уртача дәрәҗәсе (шул исәптән Татарстан Республикасы буенча уртача эш хакы дәрәҗәсенә карата да) күрсәтелә (булганда) |
| 23. | Социаль нәтиҗәлелек күрсәткече | Проектны гамәлгә ашыру процессында социаль өлкәдә ирешәчәк планлаштырылган нәтиҗә күрсәтелә |
| 24. | Икътисадый нәтиҗәлелек күрсәткече | Проектны гамәлгә ашыруның икътисадый нәтиҗәлелек күрсәткечләренең исәп-хисап күрсәткечләре (проект акча агымнарын дисконтлау ставкасының кабул ителгән мәгънәсен күрсәтеп) күрсәтелә (булганда): чиста китерелгән бәя (NPV), керемнең эчке нормасы (IRR), үз-үзен аклауның гади һәм дисконтацияләнгән вакыты (PBP һәм DPBP), табыш ин- |

| 1 | 2 | 3 |
|---|---|---|
| | | дексы (PI), рентабельлек күрсәткечләре, проектның сизгерлек параметрларын исәпләү. Булган очракта, проектның акча агымнары, салымнар һәм фондларга түләүләр, инвестицияләрне финанслау чыганаклары күрсәтелгән финанс моделе куела |
| 25. | Элемтә өчен мәгълүмат | Проектны гамәлгә ашыруга бәйле мәсьәләләр буенча оператив хезмәттәшлек итү өчен контакт мәгълүматларын күрсәтергә |
| 26. | Өстәмә мәгълүмат | Проект буенча өстәмә мәгълүмат күрсәтелә, аны инициатор дәгъва кылучы гаризасында күрсәтелергә тиешле дип саный |

Инвестиция проекты резюмеларына китерелгән белешмәләрне һәм мәгълүматны раслый торган документлар теркәлә.

Инвестор инвестиция проекты резюмеларын инвестиция проекты үзенчәлегенә бәйле рәвештә башка мәгълүмат белән тулыландырырга хокуклы.

«Шәхси мәгълүматлар турында» 2006 елның 27 июлендәге 152-ФЗ номерлы Федераль закон нигезләмәләрен үтәү максатларында физик зат яки юридик зат вәкиле тарафыннан документлар биргәндә шәхси мәгълүматларны эшкәртүгә ризалык бирелә.